# Сочинение

**Имтихан эшенең өченче бүлеге- зур булмаган күләмдә(100 сүздән ким булмаган) сочинение язу.Сочинениенең төп үзенчәлеге укылган текстны кулланып,үз фикереңне нигезләү.**

# Сочинениене ничек башларга?

Кереш өлешне язганда,кереш сүзләр һәм сүзтезмәләр белән беррәттән,түбәндәге сүзләр тезмәсен файдаланырга була:

- Текстның"..." дигән соңгы сүзләре...кебек мөһим проблема турында уйланырга мәҗбүр итә.
- Бирелгән өзекне мин болай аңлыйм: ... .
- Бу өзектә автор ... темасын яктырткан.

# Мисал

1 нче вариант

Минемчә,Ф.Яруллинның әлеге юлларында шәфкать белән батырлык кебек яхшы сыйфатларга басым ясала.

2 нче вариант

Ф.Яруллин әсәреннән алынган өзек “Батыр була бары мәрхәмәтле йөрәк!”- дигән сүзләр белән тәмамлана.Минем фикеремчә,әлеге өзектә мәрхәмәтлелекнең батырлык кебек мөһим сыйфат булуы турында сүз бара.

# Төп өлешне ничек язарга?

Алдагы адым – текстның идеясенә туры килә торган өлешләрне эзләү.

-Тесттан мисал буларак 2 дәлил китерү сорала, шунлыктан имтиханга әзерлек барышында мисалларны табып,аларны дөрес формалаштырырга өйрәтергә кирәк.

# 2 төрле ысул

- 1.җөмләләр белән өземтә(цитата)китерү.

Бу ысул, җөмләне бөтен тыныш билгеләрен саклап, төгәл күчермәсен бирүне күздә тота.

Әгәр җөмлә озын булса,төшереп калдырылган сүзләр урынына күпнокталар куеп,аның бер өлешен генә дә кулланып була.

- 2.өземтә китермичә,җөмләнең тәртип номерын гына күрсәтү.

Җөмләнең номерын күрсәткәндә,җәяләрне куярга кирәкми.Мәсәлән,(5) дип күрсәтмибез, 5 нче җөмлә яки бишенче җөмлә дип язабыз.

# Сочинениегә калыплар

- Бу фикер ... җөмләдән дә аңлашыла.
- Әйтелгән фикерне ныгыту өчен текстның ...

җөмләсен карыйк.

... җөмлә ...турында фикерне раслый.

# Йомгак өлешен ничек язарга?

- Йомгак өлешен формалаштырганда, димәк, шулай итеп,йомгаклап әйткәндә кереш сүзләрен кулланырга була.

# Җөмлә калыплары.

- Димәк,автор бүгенге көндә иң мөһим мәсьәләләрнең берсен -... күтәрә.
- Алда әйтелгәннәргә нәтиҗә ясап, шуны әйтеп китәсе килә ... .
- Бу проблеманы күтәреп, автор безне ... турында уйланырга этәрә.

# Сочинениенең якынча планы:

- беренче абзац – кереш (тезис)
- икенче абзац – тесттан алынган мисаллар һәм дәлилләр
- өченче абзац – нәтиҗә

# Истә тотыгыз!!!

- Сочинение күләме 70 сүздән дә ким булмаска тиеш.
- Эшнең әлеге өлешенә 55 минут бирелә.Әгәр  дә күчереп яза торган вакытны чигерсәк, сочинение язарга якынча 40 -45 минут калачак
- Эшкә куела торган югары балл-9.

- (1)Минем китаплар шүрлегендә тавышсыз – өнсез генә җиз кыңгырау тора.(2) Кайчандыр, моннан бик күп еллар элек, туйга яки кунакка барган чагында , ул, кара дугага тагылган килеш, ат башында йөри иде.(3) Хәзер кара дуга да юк, кара дуга белән җигелгән ат та юк, хәтта дилбегә тотып утырган хуҗа үзе дә юк, ә менә җиз кыңгырау ничектер торып, сакланып калган ... (4) Әллә нидә бер мин аны кулыма алып, әкрен генә селкеп карыйм.(5) Җиз кыңгырау шунда ук, телгә килгәндәй, дәртле тавыш чыгара:”Зың – зиң ,зың – зиң!..”(6)Нәкъ менә кара дугада чактагы шикелле чыңлап, яңгырап китә.

---

- (7) Әйе,дөньяда бөтен нәрсә искерә, туза, үзгәрә, тик менә җиз кыңгырау, ни хикмәттер, һич кенә дә бер үзгәрми.(8) Гаҗәп, вакыт дигәнең дә көчсез икән бу җиз кыңгырау алдында, ул аны әз генә дә,ичмасам, үзгәртә алмаган.(9)Ул элекечә яшь, дәртле, моңлы һәм ниндидер бер могҗиза белән мине күз ачып йомганчы кырык ел артка, яшүсмер чагыма- үземә урын таба алмыйча гел борчылып йөргән, нидер сизенеп көткән иртә яшьлегемә кайтара да куя.(10) Барысын - барысын да үтә бер ачыклык белән терелтә ул минем хыялымда... (11) Яңгырап җибәрүенә,Нигьмәтулла абзыкайның җырын ишеткәндәй булам:”Утырдым ла көймәнең, ай түренә ...”(12) Юк, кирәкми, искә төшермик.(13) Иясенә калсын ул ...
- (14) Хәзер инде бик күп яңа җырлар туды.(15) Яңа гадәтләр, яңа йолалар туды.(16) Туйларга да хәзер кыңгыраулы пар атларда түгел, ә күбрәк “Волга”, “Москвич”ларга гына утырып баралар ...(17) Әмма мәңге үзгәрми торган бер нәрсә калды: бу – кешенең яшьлеге, мәхәббәте !.. (18)Һәркемгә килә ул, һәркем кичерә аны... (19) Менә ни өчен җиз кыңгырау бик кадерле миңа: аның дәртле , көмеш тавышында гүя яшьлек һәм мәхәббәт саклана.(Әмирхан Еники)
- “Менә ни өчен җиз кыңгырау бик кадерле миңа ...” Тексттан китерелгән сүзләрнең мәгънәсен аңлатып,сочинение языгыз.